| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 10.07.2015 г. Казань № 10-15/кс

***«Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2015 елның 1 августыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы айга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручу Л.П.Борисова

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
10.07.2015 № 10-15/кс

«Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тариф

| № п/п | Муниципаль берәмлек, кайнар су белән тәэмин итүче оешма атамасы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | |
|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал |
| | | 01.08.2015 31.12 2015 кадәр | 01.08.2015 31.12 2015 кадәр |
| | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 1 | «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 35,60 | 1650,41 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 30,17 | 1398,65 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге